ГЛАВА ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

**20 март 2024 ел**

**№1**

2023 елның 20 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы гражданнары халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. “2023 елның 20 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы гражданнары халык җыенын Ләшәү Тамак авылы мәдәният йорты бинасында, Ләшәү Тамак авылы, Механизаторлар урамы урамы 1а йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 20 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү

Тамак авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Ләшәү Тамак авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ләшәү Тамак авылында Ленин урамы, буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылында триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; договор нигезендә хезмәтенә түләү) МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылы сабантуй мәйданына материал сатып алу );

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Ләшәү Тамак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы: И.З.Хабибуллин